**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең Морат торак пунктында**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**26 октябрь, 2019 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 29 октябрендә 10 сәгатьтә булган граждannар җыены нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

а) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- сүүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

б) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 97 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -58, бу 59.7% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 58 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең  Морат торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге Морат авылы территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

а) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

б) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору” соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән
Надеждино авыл җирлеге башлыгы Е.В.Савельева